СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2023 елның 13 феврале № 25/3

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, аудиторларының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының депутатларга, сайланулы вазыйфаи затларына хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары, Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 2018 елның 30 мартындагы 26/1 номерлы (2018

елның 11 маендагы 27/3, 28.09.2020 № 1/5, 03.02.2022 № 16/1, 10.11.2022 № 22/3, 14.12.2022 № 23/9 редакциясендә) карарының **1 нче кушамтасына**:

«Авыл җирлекләре башлыкларына, айлык акчалата бүләкләүдән тыш, хезмәт өчен түләүнең 11 төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекләр башлыклары өчен - елына 5,55 айлык акчалата бүләк, - хезмәт өчен түләүнең 12 төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекләр башлыклары өчен - елына 4,65 айлык акчалата бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә. Хезмәт өчен түләүнең 10, 11 төркемнәренә кертелгән аларның урынбасарлары өчен - елына 8 айлык акчалата бүләкләү, хезмәт өчен түләүнең 12 төркеменә кертелгән аларның урынбасарлары өчен - елына 6,64 айлык акчалата бүләкләү.» абзацын киләсе редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Авыл җирлекләре булып торучы муниципаль берәмлекләр башлыкларына, айлык акчалата бүләкләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, түбәндәге бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә:

- хезмәткә түләүнең 11 төркеменә кертелгәннәргә – елына 10,36 айлык акчалата бүләкләү;
- хезмәткә түләүнең 12 төркеменә кертелгәннәргә – елына 9,26 айлык акчалата бүләкләү.

Авыл җирлекләре булып торучы муниципаль берәмлекләр Башлыкларының урынбасарларына айлык акчалата бүләкләүдән тыш, ай саен акчалата бүләк, түбәндәге бүләкләүдән артмаган күләмдә түләнә:

- хезмәткә түләүнең 10, 11 төркеменә кертелгәннәргә – елына 10,69 айлык акчалата бүләкләү;
- хезмәткә түләүнең 12 төркеменә кертелгәннәргә - елына 9,18 айлык акчалата бүләкләү.».

2. Әлеге карар кул куелган көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров